СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИЖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАӘЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

*6 июнь, 1997ел.*
*ҖОМГА*

*Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга.* | *№ 61 (8073)* | *Бәясе билгеләнгәнчә*

# ЭШЛӘГӘНГӘ - ЭШ ҖИТӘРЛЕК

## «Уңыш - 97» матбугат үзәге хәбәр итә

**Шикәр чөгендере кырларын эшкәртүгә керешкән хуҗалыклар саны арта бара. Чәчүлекләрне шаровкалау, үсемлекләрне сирәкләү үткәрелгән гектарлар саны ишәйгәннән- ишәя. Авыл хезмәтчәннәре башка эшләрне дә читка куймыйлар. Пар җирләренә органик ашлама чыгару буенча бара торган удар айлык дәвамында меңнәрчә тонна органика ферма яннарыннан басуларга күчте инде. Чиста пар җирләре бар яктан да чиста булсын дисәк, ашламаны үзвакытында таратып туфракка кертү һәм кырларны чүп басып киткәнчегә кадәр эшкәртеп чыгу турында да кайгыртырга кирәк.**

**Терлек азыгы хәзерләү турында да чынлап торып кайгыртыр чак. Шуңа күрә дә районның өч кустында берьюлы шушы мәсьәләгә багышлап махсус семинарлар үткәрү юкка түгел иде. Инде витаминлы үлән оны ясау агрегатларын эшләтә башлаган хуҗалыклар да бар, күпьеллык үлән басуларында да чапкыч агрегатлар күренә. Минераль ашлама белән тукландырылган, табигать тарафыннан да, ясалма юл белән дә шактый мул сугарылган ул кырларда быел печән дә, димәк эш тә җитәрлек булачак.**



Һәр көн шулай: таңнан торып инде җан дустына әйләнгән ГАЗ - 53енең руле артына утыра да, кичке караңгыга кадәр аннан төшми Ринат. Елның төрле фасылында төрле эш - язын амбардан орлык ташу дисеңме, ашлама кайтарумы, урып - җыюда катнашумы - кыскасы авыл хуҗалыгында аңа зур җаваплылык таләп итә торган гамәлләрне башкарырга туры килә. Эшнең кайсы да хөрмәтле дип саный ул үзе, җиренә җиткереп башкарырга гына кирәк, ди һәм практикада да шул фикереннән тайпылмый.

Дөрес, авылда мәшәкатьле, борчулы үзгәртеп корулар чоры. Ул яшәгән Мамык авылы хуҗалыгы да районның «Агрохимсервис» акционерлык җәмгыяте белән берлектә проблемаларны бергә күтәреп яши башлады. Мамыклылар киләчәктә бу күренешкә өмет багъласалар да, үзләренең тырышлыгы, үҗәтлеге беренче роль уйнавын аңлыйлар. Һәрхәлдә шофер Ринат Әхмәдуллович Гобәйдуллин шундый рухта эшли.

**Рәсемдә: «Агрохимсервис» ярдәмче хуҗалыгы шоферы Р.Гобәйдуллин.**



## Хөрмәтле укучыларыбыз!

**«Дуслык» («Дружба», «Туслах») газеталарына икенче яртыеллыкка язылу бәясе дә элеккечә, ягъни 23.400 сум көенә калды. Район газетасына язылып куйсагыз, ел ахырына кадәр райондагы хәлләр турында хәбәрдар булып торачагыгыз көн кебек ачык - анысына без ышандырабыз.**

***Дус булыйк, «Дуслык»лы булыйк!***

# Иртәгә - Сабантуй!

**Инде хәбәр иткәнебезчә, иртәгә, 7 июньдә аэропорт мәйданында традицион бәйрәм - Сабантуй була.**

**Анда район халкын һәм кайткан кунакларны гаять бай программалы тамаша: ат чабышлары, милли көрәш, башка төр спорт ярышлары да, үзебезнең осталар һәм республикада танылган сәхнә йолдызлары катнашында зур концерт программасы да көтә.**

**Бәйрәмдә һәркем үзенең күңеленә хуш килердәй шөгыль дә таба алачак, дуслары белән очрашу шатлыгы да кичерәчәк. Кадерле якташлар һәм кунаклар, Сабантуйга рәхим итегез!**

***Бәйрәм иртәнге сәгать 9да башлана, сәүдә рәтләре 7дән гөрләячәк.***

# САБАНТУЙГА - ХЕЗМӘТ БҮЛӘКЛӘРЕ

**Районыбызның терлекчеләре традицион бәйрәм - Сабантуйга хезмәттә зур казанышлар белән киләләр. Хуҗалыкларда малларның продуктлылыгы көннән - көн артуга баруы турында алдагы саннарда гына җентекләп язган идек. Малларны карау һәм ашатуның технология таләпләрен төгәл үтәү, бигрәк тә җәйге лагерь чоры мөмкинлекләрен бик вакытлы файдалану, терлекчеләрнең үз вазифаларын башкаруга мөнәсәбәте кискен яхшыру нәтиҗәсе буларак, сөт җитештерүчеләр биш айда бер сыердан 1331 килограмм сөт савып, малларның продуктлылыгын узган елгыдан 391 килограммга арттыруга ирештеләр. Шул исәптән майда продуктлылык 341 килограмм булды (былтыргысы 222). Бу хәзерләүләр пунктларына килешү йөкләмәсендә каралган 96000 центнер урынына 117725 центнер продукция тапшырырга мөмкинлек бирде. Шулай итеп терлекчеләребез Сабантуйны дәүләткә сөт сатуның яртыеллык заданиесен 123 процентка үтәп каршылыйлар. Биш айда хәзерләнгән сөт күләме узган елның шул чорындагыдан 36360 центнерга күбрәк булды.**

**Хезмәт җиңүенә дәүләткә 7670 - 8430 центнер продукция тапшырган Синдряков исемендәге, Хафизов исемендәге, Мичурин исемендәге, «Киекле» хуҗалыклары, дәүләткә ике план күләмендә сөт саткан «Кондырча», яртыеллык планны күпкә арттырып үтәгән Якты Күл, «Рассвет, Кузнецов исемендәге, «Чирмешән»,»Родина»,»Тәрнәс»,»Заветы Ильича» КХАлары, «Агрохимсервис», шикәр заводы ярдәмче хуҗалыклары һәм башка хуҗалыклар аеруча зур өлеш керттеләр.**

**Ит сату буенча да нәтиҗәләр куанычлы. Биш айда яртыеллык заданиедә каралган 17200 центнер урынына 21625 центнер продукция реализацияләнде. «Родина» терлекчеләре дәүләт заданиесен дә ике тапкырдан күбрәккә, шикәр заводының ярдәмче хуҗалыгы аны 161 процентка, Кузнецов исемендәге КХА бер ярым тапкырга диярлек, «40 лет Победы», «Заветы Ильича», «Агрохимсервис» ярдәмче хуҗалыгы, Хафизов исемендәге, «Кондырча, «Чирмешән» һәм башка хуҗалыклар шактый арттырып башкарып чыктылар инде.**

**Терлекчеләребезне хезмәт җиңүләре белән котлыйбыз, аларга продукция муллыгы хакына фидакарь эшләрендә яңадан - яңа уңышлар телибез.**

# Көн тәртибендә - метро төзелеше

***2 июньдә шәһәр хакимиятендә Казан метрополитенын төзү программасын тормышка ашыру мәсьәләләре тикшерелде.***

Киңәшмәдә Казан мэры Камил Исхаков чыгыш ясады. Ыгы - зыгылы сәгатьләрдә аерым урамнарда пассажирлар ташкыны 25 мең кешегә җиткән, җәмәгать транспортының уртача тизлеге сәгатькә 10 - 12 чакрым булган миллион кешеле шәһәрдә метро төзү ихтыяҗын аңа җитди комиссия алдында нигезләргә туры килде. Татарстан Президенты М.Шәймиев, Премьер - министр Ф.Мөхәммәтшин, күп кенә министрлык һәм ведомство җитәкчеләре оппонентлар булып чыгыш ясадылар.

Казан метросының 17 чакрымлы беренче линиясе схемасы үзе үк сораулар тудырды. Татарстан Президенты фикеренчә, станцияләрнең 1,8 чакрым чамасы ара узган саен урнаштырылуы икътисадый яктан максатка ярашлы түгелдер. Кыска араларда поездлар тиешле тизлектә бара алмый, ә башкала үзәгендәге зур мәйданнарның станцияләр коруга тотылуы акланмый. Быел беренче линияне төзүгә чыгымнар 58,8 миллиард сум тәшкил итә. Аның 50 проценты федераль бюджеттан каплана. 29,4 миллиард сумы инде республика бюджетына кертелгән. Планлы рәвештә финансланса, эшкә кушылырга тиешле линияне төзү 2004 елга төгәлләнергә тиеш Шуннан соңгы ике линия 2023 елга төзеләчәк. Минтимер Шәймиев, үзен пассажир роленә куеп, шәһәрнең үзәк өлешендә метроның өч тармагын бергә тоташтыруга карата искәрмәләрен әйтте.

(«Шәһри Казан»нан).

## Яртыеллыкны - срогыннан алда

«Вторчермет»ның Норлат - Октябрь цехы коллективы тимер - томыр эшкәртү һәм аны металлургларга озату буенча беренче яртыеллык заданиесен вакытыннан алда башкарып чыгуга иреште. Соңгы елларда цех акционерлык берләшмәсе составына керүче 13 цех арасында иң яхшылар исәбендә йөри. Аз санлы бу коллектив Октябрь районыннан тыш тагын жиде районга хезмәт күрсәтә. Безнең районда «Норлатнефтеразведка» ОООсы, НГДУ, кайбер ассоциацияләр металл ватыклары тапшыру буенча ярыйсы гына эшлиләр. Цехның инде өченче ел үзара килешүләр нигезендә эшләү практикасын куллануы да уңай нәтиҗә бирә.

# Әйдәп баручылар

Мичурин исемендәге кооперативлар берлеге савучысы Валентина Васильевна Тимофееваның хезмәт көне иртә таңнан башлана. Шулай вакыт белән санашмый эшләү, малларын жиренә җиткереп карауның нәтиҗәсе дә менә дигән. Биш айда үз группасындагы маллардан барлыгы 468 центнер продукция алуга иреште ул, сыерларының уртача продуктлылыгы 1875 килограмм булды. Унган терлекченең хезмәттәшләре Людмила Николаевна Михеева белән Анастасия Федоровна Ивашкина да аннан күпкә калышмыйлар - алар группаларындагы сыерлар биш айда 1868 - 1845әр килограмм сөт биреп куандырды. Савучыларның тырышлыгы, бар осталыкларын куеп эшләве әнә шулай күркәм нәтиҗәләр бирә. Ярышта әйдәп баручы тәҗрибәле савучыларга хуҗалыктагы башка терлекчеләр дә тигезләнәләр. Шуңа да, уртак хезмәт нәтиҗәсе буларак, биредә бу көннәрдә бер сыердан 19 килограммнан күбрәк сөт савыла.

Т.АЛЕКСЕЕВА.

*Җир турында сөйләшәбез*

## 3. Норлат - гаражлар шәһәреме?



Хөрмәтле шәһәрлеләр! Язма башында ук сезгә сорау белән мөрәҗәгать итәргә булдык: шәһәребез нинди объектларга бай? Иманым камил: гаражлар һәм тавык кетәклекләре дип җавап бирерсез, мөгаен. Ә моның киресен расларга теләүчеләр булса, гараж, тавык оялары «камалышы»нда калмаган бер генә йорт адресын булса да әйтсеннәр иде.

Сүз дә юк, Норлатыбыз шундый объектлар белән чүпләнеп, чуарланып беткән. Төзелеш оешмалары йортны файдалануга биреп тә өлгерә алмыйлар, яңгырдан соңгы гөмбәләр кебек гаражлар үсә дә чыга. Әнә, чагыштырмача яңа микрорайон саналган К.Маркс проспектындагы 1 нче, һәм шул тирәдәге өч һәм биш катлы йортлар яннарында, шунда яшәүче гаиләләр санынча гаражлар төзелде инде. Техникасы бармы, юкмы, әмма кеше гаражын сала. Ярый ла тирәләрен карап - чистартып торсалар. Юк шул. Әле еш кына алар янгын чыгуга сәбәпче дә булалар. Шәһәр Советы да, архитектура бүлеге дә һ.б. моңа күз йомгач, ник төземәсеннәр ди инде аны. Зур шәһәрләрдә гараж урыны өчен кесәңнән шактый акча чыгарып салырга кирәк булыр иде, ә биредә... бушка рәхәтлән! Шәһәр архитектурасы ни дә, чисталык - матурлык ни алар өчен. Иң мөһиме гараж булсын, һәм... подъезд төбендә булсын.

Шулай да бу хуҗасызлыкка чик куелырга тиештер бит. Тиеш дигән катгый карарга килеп, ике еллап элек архитектура бүлеге законсыз төзелгән гаражларны трактор белән басу кырына да чыгарып карады. Әмма эш шуннан узмады: гаражлар үз урыннарында калды, яңалары тагын да күбрәк төзелде.

Быел җир ресурслары һәм җир реформасы буенча район комитеты, район хакимиятенең архитектура бүлеге, район эчке эшләр бүлегенең янгын часте, дәүләт санэпидкүзәтү үзәге һәм МПП белән берлектә җирне законсыз «басып» алып төзелгән гаражларны алдыру максатыннан тикшерү үткәрде. Аның барышында байтак фактлар ачылды. Һәм, әйтергә кирәк, аларның барысы буенча да катгый чаралар күрергә ниятли комиссия. Башта гараж хуҗаларына кисәтү - күрсәтмә бирелә. Ул үтәлмәгән очракта хезмәткә түләүнең 2 - 5 минималь хакы күләмендә штрафка тартылалар. Бу чара аларга җирне законсыз «басып» алган өчен кулланылачак. Әмма «җәза» моның белән генә дә бетмәячәк әле: комиссия карарына буйсынмаучылар эше район хакимияте башлыгы каршындагы административ комиссиягә җиткереләчәк. Ә комиссия инде аерым эшләрне прокуратурага да тапшырырга мөмкин.

Комиссия әгъзалары ышандыруынча, мондый чаралар үзмаксат түгел, ә бәлки өлгергән һәм хәл итүне таләп итүче бурыч. Шуны да әйтәсе килә, район хакимиятенең архитектура бүлеге шәһәр читендә гаражларны махсус урынга туплауны күздә тота. Һәм бу мәсьәлә якын көннәрдә очланырга да тора.

Әмма шулай гына итеп, әлеге проблеманы хәл итү мөмкинме соң? Бәлки, мөмкиндер. Анда - санда төзелгән гаражларның кайберләре законлы статус алып, икенчеләрен (әгәр мөмкин булса) читкә чыгарып кына шәһәр архитектурасы үзгәрсә дә, урамнар тәртипкә керсә икән ул. Шәһәр җитәкчелегенең үзвакытында бу проблемага әллә ни зур игътибар бирмичә, сораган бер кешегә карар «тоттыруы», МПП, шулай ук ведомстволы территорияләр хуҗалары - ЖКХлар «массовый төстә» гаражлар төзелә башлаган бер вакытта аларның законсызларына карата катгый чаралар күрмәве, ахыр чиктә, гаражлар төзү өчен җитәрлек итеп махсус урыннар бүлеп алынмавы (бүгенге көндә 5 гектар гына) бүген күпме хезмәт структуралары хезмәткәрләренең төп эшләрен мәшәкатьләде, кулымда шәһәр Советы карары бар дип яисә чүлмәкчедән күрмәкче дигәндәй, кеше төзи бит - миңа да ярый дип кайчандыр гараж төзеп куеп тынычланган күпме шәһәр халкының бүген исә күңеленә шөбһә салды.

(Дәвамы 3 нче биттә).

**Р.ГИНЯЕВА.**

## Җәй - мул сөт чоры



Уртак эш кешеләре алар - халыктан сөт җыялар. Насыйх ага пенсиягә чыккач, унике ел элек тотынган иде бу эшкә, Илһам Хафизуллинның да тәҗрибәсе байтак, элегрәк сөт ташу машинасын йөрткән кеше буларак, сөт җыю эшенең рәтен - чиратын белә. Әле кышын, Насыйх ага какшабрак торганда авылның ул йөри торган очын да әйләнергә иренмәде.

Беренче карашка гына бер кыенлыгы да юк кебек бит ул эшнең - иртән иртүк атыңны җигеп чыгып кит тә, өй саен туктап сөтләрен үлчәп сала бар һәм әзер машинага авыштырып сөт - май комбинатына озат һәм эшең бетте. Әмма, һәр эштәге кебек үк, аның вагын -төяген аны үз куллары белән башкарган кеше генә белә шул. Ә сөт җыю кебек эштә андый «вак - төяк»ләр шактый һәм шулар арасында иң четреклесе - продукциянең сыйфатлы булуы, ягъни дәүләт стандарты таләпләренә җавап бирүе. Күмәк хуҗалык фермасында сыйфатны берничә савучыдан гына сорарга кирәк булса һәм өстәвенә анда махсус лаборант та булгач, җавап бирер кеше анык билгеле. Ә менә шәхси хуҗалыклардан җыелган сөтнең хуҗасы йөзләгән, шуңа күрә сөт җыючы аеруча игътибарлы да, таләпчән дә булырга тиеш. Ул яктан Кычытканлыда сөт җыючыларга бирәүнең дә үпкәләрлеге юк - кемнең сыерының сөте куерак, кайсы хуҗабикәнең эшкә арурак булуын, кемнең хәйләкәрлек күрсәтергә мөмкинлеген белеп торалар. Шунсыз ярамый да, бирәүнең өсте алынган яки тәм кергән сөтен кушып бөтен җыйналган продукцияне әрәм итмәссең бит инде, ә аннары шул бирәүнең гөнаһысын бөтен кеше уртаклашырга мәҗбүр була. Әле бит күпме продукция юкка чыгарга мөмкин. Ул яктан Кычытканлыда элек - электән сөт күп җыела - бу көннәрдә сөт - май комбинатына 1200 - 1300 килограммга кадәр продукция озатыла. Шуңа күрә дә биш айда җыелган барлык сөт 770 центнер булып, беренче яртыеллыкка җиткерелгән заданиенең инде хәзер үк 160 процентка үтәлүе гаҗәп түгел. Бер сыер башына җыелган сөт 392 килограмм. Хәер, акчасын вакытында түләп баргач, халык сөтне бик теләп тапшыра. Фаварис Мингалимов, Рәфыйк Хуҗиәхмәтов, Рәисә Гыйниятуллина, Мингаяз Шаһивәлиев, Әүхәт Исхаков һәм башка бик күпләрнең тапшырган сөтләре уртача күрсәткечтән шактый артык.

Әнә шулай, җирле үзидарә Советы, хуҗалык җитәкчелегенең бу эшкә игътибар бирүе, сөт җыючыларның тырышлыгы һәм халыкның активлыгы белән Кычытканлыда шәхси сектордан сөт җыюның оештырылуы башка бик күпләргә үрнәк булырлык.

**Рәсемдә: сөт җыючылар И.Хафизуллин (сулда) һәм Насыйх Шәһитов.**

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

> ***Безнең районда имгәнүләр ни дәрәҗәдә, андыйларга үзвакытында квалификацияле медицина ярдәме күрсәтеләме? Газета битләрендә шул хакта сөйләсәгез иде.***
>
> ***А.Яруллин.***
>
> ***Норлат шәһәре.***

## Имгәнүнең ахыры яман



**Без бу хакта район үзәк шифаханәсе травматологы Игорь Васильевич ВОЛКОВНЫҢ сөйләвен үтендек.**

Соңгы елларда имгәнүләр актуаль проблемага әйләнде. Ул түбәндәге шартларга бәйләнгән: симптоматиканың төрле органнар җәрәхәтләнүе белән бәйле рәвештә катлаулануы аркасында клиниканың аерата кыенлыгы; аерым төрле җәрәхәтләрнең билгесе һәм дәрәҗәсе симптомнар белән тәңгәл килмәгәнгә күрә диагностиканың кыенлашуы да моңа сәбәпче булып тора. Кайбер очракта бәлага таручылар аңсыз хәлдә булалар, шунлыктан өстенлек алучы җәрәхәтне билгеләве дә ансат түгел.

Имгәнүләрнең 50 - 70 проценты үлем очраклары белән тәмамлануы бер яктан җәрәхәтләрнең төзәлмәслеге белән аңлатылса, икенче яктан үзвакытында квалификацияле медицина ярдәме күрсәтелмәүгә дә бәйле. Иң авыр имгәнүләр арасында беренче урынны автотранспортта имгәнүләр өченче урынны тәшкил итә. Шулай, производствода булмаган имгәнүләрнең 40 - 60 проценты исерек хәлдә килеп чыга. Шул сәбәпле исерек хәлдәге кешенең кайчак имгәнү дәрәҗәсен ачыклау да кыенлаша.

Транспортның һәр төрендә имгәнүләр төрле була: җиңел машиналарда күпчелек очракта гәүдәнең дисталь өлеше - аяклар, йөк машиналарында - проксималь - балтыр, оча сөяге, оча - балтыр буыннары, күкрәк читлеге зыян күрә. Ә мотоциклда саклану чаралары бик аз булганга, имгәнүләр тагын да катлаулырак - анда ачык типтагы сынулар өстенлек ала. Автотранспорт әйләнгәндә еш очракларда кабыргалар, умыртка сөяге сынуы күзәтелә. Имгәнүләрне дәвалау бик катлаулы процесс һәм күп вакыт операциясез гамәлгә ашырылмый. Бәхеткә каршы, соңгы вакытта безнең район үзәк шифаханәсендә Татарстанның зур шәһәрләрендәге травматологик бүлекләр дәрәҗәсендә квалификацияле травматологик ярдәм күрсәтү мөмкинлеге туды һәм ул күрсәтелә дә. Шифаханә администрациясе тырышлыгы белән Илизаров аппараты, микрохирургия җайланмасы булдыралдык. Нәтиҗәдә скелетны сузу, гипс лангетлары кебек иске ысуллар артка кала бара, хәзер аяк һәм кулларның ачык һәм ябык типтагы барлык төрдәге имгәнүләрен дә дәвалауда Илизаров аппаратыннан файдаланабыз. Әлбәттә дәвалану вакыты да күпкә кыскара. Кагыйдә буларак, шулай дәваланучыларга алга таба Иске Чаллы шифаханәсендә дәвалануны дәвам итү максатында юллама бирелә. Быел хирургия бүлегендә 182 авыру дәваланды, шуларның 38е баш сөяге - баш мие җәрәхәтләнүе, 72се кулы, 52се аяклары сынып, 12се умыртка сөяге имгәнүе белән ятты. Ә 8 кеше берничә төрле имгәнүдән дәваланды.

Еш кына авырулар арасында җиңелчә генә баш сөяге имгәнүен игътибарсыз калдыралар. Ләкин шунысын әйтергә кирәк, баш сөягенең җиңелчә генә беренчел җәрәхәтләнүе алга таба баш сөяге эчендә каты авыру формалашуына, баш мие агып чыгуына китерергә мөмкин. Шуңа күрә һәртөрле имгәнүгә җитди карап, үзвакытында шифаханәгә мөрәҗәгать итәргә һәм имгәнү дәрәҗәсен ачыкларга кирәк, шул чакта гына нәтиҗәле медицина ярдәме алуга ирешергә була.

Статистика мәгълүматлары күрсәткәнчә, транспортта имгәнүләр елның җәйге - көзге чорында аеруча ешая. Ә тәүлек буенча чагыштырганда, һәлакәтләрнең «пигы» кичке сәгать 6га туры килә. Имгәнүләрнең иң авырлары күплеге дә юл - транспорт һәлакәтләрендә имгәнүләр өчен характерлы күренеш. ВОЗ (Бөтендөнья сәламәтлек саклау җәмгыяте) мәгълүматлары буенча дөнья юлларында һәм урамнарында һәр 2 минутка бер кеше үлә, һәр 5 секундка бер кеше инвалидка әйләнә. Һәлак булучыларның 20 проценты квалификацияле табиб ярдәме күрсәтелгәндә исән калырга мөмкин дип исәпләнә.

Шунысын әйтергә кирәк, имгәнеп үлүчеләрнең яше 20 - 40та тирбәлә, димәк халык хуҗалыгы өчен дә бу күренеш зур зыян алып килә һәм имгәнүләрне профилактикалауны һәм бәлага таручыларны дәвалауны оештыруның никадәр әһәмиятле булуы хакында сөйли.

Көнкүрештә имгәнүләр

## Продукция артса иде

Безнең Яңа Әмзә товарлыклы - сөтчелек фермасының җәйге лагере гаҗәеп матур урында урнашкан. Чиста сулы киң елгасы, тез тиңентен үләнле яшел болыннары бар. Карда үзе дә ремонтланган - каралган. Рәхәтләнеп эшлә генә! Әмма соңгы вакытта хуҗалыгыбызда малларының продуктлылыгы кимү генә күңелне төшерә бераз. Югыйсә халык та тырыш, максатчан безнең. Әнә, 1969 нчы елдан бирле фермада эшләүче Җария Шәрәпова, аңардан азга гына яшь Әкълимә Исхакова, Әлфия Хуҗина, авылыбызга Морасадан килен булып төшкән уңган булган Сания Вәлиева, Румия Мифтахова, Венера Нуриева, Рәмзия Зәйниева, Фәүзия Мокъсинова нинди тырышлар. Әле менә җәйге лагерьга чыгу уңаеннан оештырылган чарада да элек бергә эшләгән елларны искә төшереп кенә калмыйча, соңгы елларда продуктлылыкның ни өчен кимүен дә анализладык: фермаларда нәсел эшен төптән үзгәртмичә торып, әллә ни зур продукциягә исәп тотып булмастыр, дигән уртак нәтиҗәгә килдек. Әмма моның бер көндә генә башкарырлык эш түгеллеге барыбызга да мәгълүм. Шулай да кызлар тырыша. Маллар көндез көтүдә йөриләр, бер үк вакытта алар кышкы рацион нигезендә ашатыла әле. Ә азык җитәрлек. Ферма мөдире Надыйр Мәхмүтов көн тәртибенең төгәл үтәлүен даими контрольдә тота. Шуңадыр инде, соңгы вакытта сөт тә бераз артты. Бу - җәйге лагерьда эшләүче һәр кешенең дә күңелен күтәреп җибәрде. Алар киләчәктә җәйге чорның һәр көнен рациональ файдаланырга, маллардан мөмкин кадәр күбрәк продукция җитештерергә исәп тоталар.

**С.ФӘТХЕТДИНОВА,**
**хәбәрче.**

## *Җир турында сөйләшәбез*

# 4. Совет хуҗа булмагач...



Авылларда Советларның гөрләп эшләгән чаклары хәтердә әле. Җир кардан арынып, бераз кипшенүгә үк, авыл Советы каршындагы махсус комиссия йорт буйлап йөри иде: утын - агачларыгызны кисегез, ярып өегез, йорт тирәләрегезне җыештырыгыз. Фәлән срокка таләпләр үтәлмәсә кара исемлеккә кертелгән фамилияңне җирле радиоалгыч буенча бөтен халык ишетәчәк. Анысы да тәэсир итмәсә, өстәмә кисәтүсез штраф суммасы хезмәт хакыннан тотыла да калына. Келәт, мунчаңны да үзеңә бүлеп бирелгән 25 сутый җиреңнән чыгарырга ярамады. Норманы азрак уздыңмы: хисапчы «саржинын» тотып килеп җитә иде.

Ә хәзер... Оят булса да килешик, авылларыбызның санитар торышы, мөгаен, моннан да начар була алмыйдыр. Һәркем үз өй янын гына кайгырта шул: шакшы су йорт каршындагы юлга түгелә, тирес тә шунда чүмәлә итеп өелә, утын, агач материалы исә кайда буш урын бар шунда ыргытыла. Ул мунча - келәтләрне байтак авылларда биләмәләрдән читкә чыгып төзү гадәткә керде. Ә чүп - чар... Урамнар елына бер тапкыр да җыештырылмый, чүп - чар читкә чыгарылмый. Хуҗасыз калган иске, ярым җимерек йортларның исерекләр җыелу урыны яки янгын чыгуга сәбәпче объект буларак уннарча ел торуы да һичкемне борчымый. Ә хуҗасыз, чүп үлән орлыклары «үрчетүгә» генә хезмәт итүче бакчалар күпме тагын?!

Гомумән, авылда җиргә мөнәсәбәт бик начар. Җир ресурслары һәм җир реформасы буенча район комитеты үткәргән тикшерү барышында да шул мәсьәлә ассызыкланды. Белгечләр раславынча, Егоркино, Чулпан, Урта Камышлы, Якушкино, Аксумла һәм башка җирле үзидарәләр территорияләре торак пунктларында тәртипсезлек аеруча күзгә бәрелеп торырлык. Моның өчен кем гаепле? Билгеле инде, беренче чиратта Советлар җитәкчеләре. Алар халык алдына катгый таләпләр куйсалар, авылларда яшәүчеләр дә үз өй эчләрендә тәртип булдыруны гына кайгыртмыйча, авыл - уртак йортыбыз дип, аның һәр карыш җирен рациональ файдаланырлар, пычратуга юл куймаслар иде.

**Р.ГИНЯЕВА.**

## *Тирәбездә*

# *Яхшы кешеләр*



Чулпан участок шифаханәсе амбулаториясендә булучылар бередә, беренче чиратта, идеаль тәртип булуын билгелиләр. Билгеле инде, шундый зур бинаны тәртиптә тоту җиңел түгел. Ни өчен дигәндә, бередә бу чисталыкны тәэмин итүче хатын - кызлар нибары өчәү генә. Шуларның берсе Исламия Җирҗизова. Пенсия яшенә якынлашып килүче бу хатын - кыз нинди эшкә алынса да, аны җиренә җиткереп, кем әйтмешли, кырып - себереп башкарып куя. Исламия идән дә юа, тузан сөртергә дә өлгерә, кирәк булганда регистратурада карточкалар эзләүдә дә аның ярдәме тия. Гомумән, Исламия ярдәмчел кеше. Хезмәттәшләренә булыша, ярдәм сорап килүче авылдашларына да кул суза. Әле менә амбулаториядә ремонт барган бу көннәрдә тыз - быз килеп бина төзәткән осталарга да булышмыйча түзә алмый.

**Рәсемдә: Чулпан участок шифаханәсе санитаркасы И.Җирҗизова.**

## *Күңел кыңгыраулары*

# Туй күлмәкле кабер

Мондый үлемне җиңел үлем саныйлар. Кулга калып ятмады, көчле авыртудан тартышмады ул. Бөтен тереклек уянып килгән май иртәләренең берсендә зур зәңгәр күзләре белән озак итеп каеннарның тузан да кунарга өлгермәгән ачык яшел төсле яфракларына, ак тәлгәшләрен җилдә тибрәтүче шомырт агачына, зәп - зәңгәр күк йөзенә карады да күзләрен мәңгелеккә йомды. Ата - ананың кайгысының иге - чиге юк иде: кызлары авырып торса да, тормышы шул кадәр тиз өчланыр дип күз алларына да китермиләр иде: 24 яшендә салкын кара җир куенына кереп ятар дип кем уйлаган бит.

Илсур белән берничә ел яратышып йөрделәр алар. Өйләнешергә дип вәгъдәләшеп, туй көнен дә билгеләделәр. Рәмзия туй күлмәге өчен тукыманы үзе сайлап алды. Үз кулым белән, үзенчәлекле итеп тегәм дип, эштән кайткан саен тегү машинасы артына утырды. Күлмәге дә, фатасы да карап туймаслык матур, зәвыклы килеп чыкты. Шуларны киеп, көзге каршысында бөтерелгәндә шатлыгы эченә сыймый иде.

Көннәрдән бер көнне үзендә хәлсезлек сизде Рәмзия: туй турында борчылуы, дулкынлануы дип кабул итеп тынычланды ата - ана. Ә инде кызларының хәле көннән - көн мөшкелләнүен күргәч, шифаханәгә барырга күндерделәр Рәмзияне. Анда кыз бер ай ятты. Билгеле инде, туй сроклары да кичектерелде. Илсур сөйгәне янына көн дә килеп йөрде. «Тизрәк савык инде»,- дия иде аның күзләре. Рәмзия генә егетеннән карашын яшерергә тырышты: йөрәгендәге әчке бер сизенү туйның булмаслыгын тоемлый иде. Бары тик йокы бүлмәсендәге стенага эленгән ап - ак ефәк туй күлмәгенә карагач кына, күңеле күтәрелеп, яшәүгә өмете үсә иде. Кечкенә чактан ук ап - ак, очыргычтай күлмәк кигән, башына ефәк ак фата бөркәнгән нәзберек кәләшләрне күрсә җаны үрсәләнә иде: менә ул да үсеп җитәр дә шул кыз кебек ак күлмәкләр киеп, сөйгәне белән ЗАГСка барыр. Ак күлмәк кигән кеше, һичшиксез, бәхетле булырга тиеш. Ул да бәхетле булыр: ул - кызлар үстерер. Хыяллар, хыяллар...

Шифаханәдән савыгып чыкты ул. Инде ата - аналар янә туй срогын төгәл билгеләргә җыеналар иде, көтмәгәндә Илсурның гаиләсенә зур кайгы килде: әнисе үлеп китте. Әмма бәла ялгыз йөрми шул: егетнең әнисенең кырыгын үткәргән көннәрдә Рәмзия тагын үзен авыр хис итте. Бу юлы авыруны аяк өстендә генә үткәрергә ниятләп, «хәл кертә, авыртуны юып ташлагандай итә», дип рекламада күрсәтелгән дарулар эчә башлады. Әмма кызның хәле җиңеләймәде. Бераздан тәнен аллергик бетчәләр басты. Ата - анасы, Илсур аны өйдә дәваланып булмаслыгына күндергәч, бик авырлык белән шифаханәгә барырга ризалашты Рәмзия.

Диагноз кую өчен табибларга берничә сәгать кенә кирәк булды: үпкәләр шактый бирешкән. Шул ук вакытта дәваларлык мөмкинлек тә юк: анализлар начар, хәтта канда гемоглобин да 60ка гына калган.

- Туй күлмәге кию насыйп түгелдер инде,- диде ул Илсурның шифаханәгә бер килүендә.

- Нык бул, терелерсең,- дип ышандырды егете кызның күзгә күренеп саргаеп, яшәү нурын югалта барган битеннән сыйпап,- барысы да алда әле.

Бу аларның соңгы очрашуы булды.

... Рәмзияне әти - әнисенең туган ягына - ерак авылга алып кайтып җирләделәр. Мәрхүмәкәй үләре алдыннан әби - бабасын, аларның яшел үләнле йортын, бакча артларыннан боргалана - боргалана аккан елгасын еш искә ала иде. Җаны - тәне шунда тартылган, мәңгелек йорты чакыргандыр инде. Шуңа да авылга җыенганда йокы бүлмәсендә эленеп торган туй күлмәген дә таслап төреп, үлемтекләр чемоданына салдылар.

- Татарда кабергә кәфенлектән башка нәрсә кую бернинди кануннарга сыймый,- дип кырт кискән мулла абзый, соңрак, мәрхүмәнең туганнары үгетләгәч, туй күлмәген кызның баш очына куярга рөхсәт бирде. Шулай авылның йөз еллык зиратында яңа, туй күлмәкле кабер барлыкка килде.

**Р.ӘКЪРАМОВА.**

# Йөзеннән нур сибелә

Бу хатын - кызның йөзендә һәрчак елмаю балкый. Мондый кешенең йөзенә карауга ук: бу бәхетле, һичнинди проблема белмәүче кешедер дип уйлыйсың. Ә инде сөйләшә китсәң, бу кешенең дә барыбызныкы кебек үк проблемалары булуына инанасың. Рушания апаның башына да аз төшмәделәр алар: баштарак Казахстанда яшәделәр, үзлектән пешекче һөнәрен үзләштерде. Аннары таныклык алгач 10 ел дәвамында берөзлексез аш - су белән эш итәргә туры килде.

Норлатка күчеп кайткач та, Рушания Фәхриева һөнәр алыштыру турында уйламады. Башта беренче ашханәдә эшләде, соңгы 6 елын җәмәгать туклануы предприятиесенең өченче номерлысында. Кемгәдер, пешекче хезмәте әллә ни катлаулы да булып күренмәскә мөмкин. Әмма көне буе кызу плитәләр, зур авыр кәстрүлләр янында әвәрә килгән кеше моны үзе генә беләдер. Шуңадырмы, эш режимы да үзгә аларның: биш көн эшләп, биш көн ял итәләр. Ярый ла, коллективың яхшы булса. Ә Рушаниягә гомер буе яхшы кешеләр юлдаш булды. Әнә, соңгы елларда бригадирлары Нәсимә Вәлиәхмәтовна Хуҗахановадан да уңдылар. Ипле, җайлы кеше. Аның да хезмәт биографиясе түгәрәкләнеп килә: берничә айдан лаеклы ялга китәсе. Савыт - саба юучы Елизавета Петровна Мандрейкинага да пенсиягә китәргә санаулы айлар гына калды. Гомумән, бригададагы дүрт кешенең һәркайсы да әйбәтләр, теләсә нинди очракта бер - берләрен алыштыра алалар. Эшләрендә элеккеге киеренкелек басылса да, ашханә юл өстендә булу сәбәпле, бирегә тамак ялгарга дип керүчеләр аз булмый. Пешкән ашны суытмаска, халыкның барлык ихтыяҗын да тулы канәгатьләндерергә кирәк. Кәефең нинди булуга карамастан, бирегә кергән һәр кешегә ачык йөзеңне дә, тәмле телеңне дә кызганма әле өстәвенә. Ә Рушания апаның ул яктан күңеле тыныч: йөзенә «ясалма» елмаю чыгарып, төче теллеләнеп азапланасы юк: йөзе һәрчак елмаюдан балкып тора аның, теленнән дә һичкайчан авыр, үпкәләтерлек сүз төшмәс. Эшендә генә түгел, өендә дә шундый ул. Ире - нефтьче Рафаэль белән тату гомер кичерделәр, инде балалары үзләре дә әти - әниләр булдылар. Румия - шәһәрнең беренче мәктәбендә укыта, улы Равил Түбән Кама шәһәрендә яши, заводта эшли. Алар да әти - әниләре кебек үк тормыштан ямь табып яшәүчәннәр. Ә бу сыйфатлары өчен алар иң элек әниләренә бурычлыдыр, мөгаен. Бүгенге тормышта аздан да күңел булып, аздан да канәгатьләнү алып яшәүчеләр күп булмаса да, бар алар. Әле менә Рушания апаны лаеклы ялга озату уңаеннан кичәгә җыелган хезмәттәшләре, дуслары да билгеләделәр аны, үзләренең дуслары, остазларының киләчәктә дә шундый булып калуын теләделәр.

**Р.МИНАПОВА.**

**Мөнәвәрә УСМАНОВА**

# *Яшьлек кайтавазы*

Тагын язлар килде,
Бакчама ямь керде,
Алмагачлар ап - ак чәчәктә.
Кузгала дәжан да тирән хисләр
Хыялларга чумам шул чакта.

... Ул чакта да ямьле язлар иде,
Йөргән идек чыкка чыланып,
Яшел үзәндәге томаннарда
Калган идек икәү югалып.

Яшел хәтфә кырда
Эшләп йөрдек бергә
Каршыладык күпме таңнарны,
Әллә язмыш, әллә ялгыш булды -
Якын иттек чит - ят ярларны.
Хәзер сиңа мин ят,
Миңа - син ят,
Мәрхәмәтсез булды язмышлар,
Йөрәгемдә калдың
Тәүге сөйгән ярым,
Җаным тулы әрнү - сагышлар.

## Тирәбездә яхшы кешеләр

# ОСТАЗЫБЫЗ УЛ БЕЗНЕҢ

Еш кына безнең картлыгыбыз үзебезнең балаларыбызны ничек тәрбияләвебезгә бәйле. Әмма балаларыбызны без ата - аналар гына түгел, ә алар йөргән учреждениеләр хезмәткәрләре дә тәрбиялиләр бит. Минем уйлавымча, балачакларында Валентина Петровна Иванова белән аралашкан, аңарда тәрбияләнгән нәниләр үсеп җиткәч тупас, усал була алмаганнардыр, мөгаен. Ул 35 ел берөзлексез Норлат тимер юл станциясенең балалар бакчасын җитәкләде. Үз карамагындагы коллективны иҗади эшләргә, үз вазифаларына җаваплы карарга өйрәтте. Үзендә тәрбияләнүче нәниләргә исә мөнәсәбәте үзенчәлекле, аеруча җылы иде: кешеләр белән аралашырга, яхшылыкка, игелеккә өйрәтте ул аларны. Балаларны кече яшьтән хезмәткә өйрәтүне дә үзенең төп бурычы санап, педагогларга да шуны төшендерергә омтылды. Таләпчән җитәкче, оста тәрбияче акыллы хатын - кыз буларак та коллективның абруен яулады ул. Бу кешенең җан җылысы балалар белән тәрбиячеләргә генә түгел, ата - аналарга, аның белән аралашкан башка кешеләргә дә җитәрлек булды. Районның мәктәпкәчә учреждениеләре хезмәткәрләренең байтагы да үз хезмәтләрендә аның эш тәҗрибәләрен нигез итеп алдылар. Шуңа да аның юбилеен билгеләп үткән бу көннәрдә без остазыбыз Валентина Петровнаны җитәкче, педагог, ана буларак та һәрберебез өчен үрнәк булганы өчен хөрмәтебез, мәхәббәтебезне белдереп, аңа киләчәктә картаймас күңелле булып калуын, сәламәт булып, озак яшәвен телибез.

**Р.ХӘСӘНШИНА,**
**РОО методисты.**



Сәвия Хәсәновна балалар белән ике дистә елга якын эшли. Баштарак тәрбияче иде ул, соңгы елларда үзе эшли торган МСОның «Чыршыкай» балалар бакчасында тәрбияләнүчеләргә татар теле укыта. Табигате буенча үтә сабыр, тыйнак ул. Балаларга мөнәсәбәте исә аналарча. Сәвия Хәсәновна үсеп килүче яшь буын күңелендә татар теленә мәхәббәт хисләрен ныгыту, аларны үз милләтләренең патриотлары итеп тәрбияләү өчен күп көч куя ул.

**Рәсемдә: С.Х.Мусина.**
**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

# ЫШАНЫЧЛЫ ПАРТНЕР

Тормыш күрсәткәнчә, янгын, җил - давыл, су басу, башка табигать бәлаларыннан, урлашулардан беркем дә гарантияләнмәгән. Шул уңайдан халык, колхоз, совхозлар, предприятиеләргә страхование хезмәте күрсәтү аерым урын алып тора. Бездә исә халыкның мөлкәт мәнфәгатьләрен Татарстанда бердәнбер булган «Росгосстрах - Татарстан» дәүләт страховой фирмасы аркылы страховать итеп була. Ә аның филиалы районыбызда да бар.

Закон нигезендә гражданнар хуҗалыкларында төзелешләр (йортлар, сарайлар), мөгезле эре терлек мәҗбүри страховать ителә. Әмма барлык төзелешләр дә түгел, ә бәлки даими урынга урнаштырылганнары, стена һәм түбәсе булганнары гына. Иске һәм җимерек төзелешләр, шулай ук хуҗаларының адреслары билгеле булмаган төзелешләр страховать ителми. Мәҗбүри страховать ителергә тиешле төзелешләр төзелгән көннән таушалуын исәпкә алып бәяләренең 40 проценты күләмендә страховать ителәләр.

Авыл җирендә төзелешләр аның хуҗасы гаризасы нигезендә филиал белгечләре тарафыннан урында карау һәм үлчәү белән билгеләнә. Шәһәрдә бу эш техник инвентарьлаштыру бюросы аркылы башкарыла. Бу бәяләү страхованиенең әлеге төренең һәр объекты өчен страхование суммасы булып тора. Хуҗалыктагы бар терлек тә мәҗбүри страховать ителергә тиеш. Төзелеш һәм терлекләр буенча страхование түләү ставкалары бер елга 100 сум страховой суммадан чыгып билгеләнә (төзелеш - 0,4, мөгезле эре терлек - 4,5, атлар - 5).

Мәҗбүри страхование буенча түләүләр бер вакытта, страховой таныклыкта билгеләнгән срокта кертелергә тиеш. Вакытында түләү үткәрелмәгәндә һәр көн өчен пеня билгеләнә.

Гариза һәм җирле үзидарә Советы карары нигезендә аерым гражданнар түләүләрдән тулысынча яки өлешчә азат ителәләр. Андыйларга ялгыз, карт, авыру, сукыр һәм чукрак кешеләр керә. 1997 нче елдан Бөек Ватан сугышында катнашучылар өчен льготалар бетерелә.

Страховой фирма филиалы төзелеш, терлек, мөлкәт, транспорт чаралары, гражданлык җаваплылыгы, шулай ук тормышны һәм сәламәтлекне страховкалау, балалар, мәктәп укучыларын бәхетсезлек очракларыннан, предприятиеләр исәбеннән эшчеләр һәм хезмәткәрләрне бәхәтсезлек очракларыннан страховать итү кебек ирекле төрләрен дә тәкъдим итә.

Страховой фирма филиалы страховкалауның барлык төрләрен дә кертеп, төрле предприятиеләр һәм гражданнар белән 25.000нән артык килешү төзеде. Страховать ителгән кешеләргә үзвакытында һәм төгәл итеп хезмәт күрсәтү, районда страхованиенең барлык ирекле төрләрен тигез үстерүгә ирешү - безнең филиалның бурычы булып тора. Без бер генә страховой вакыйганы да игътибарсыз калдырмыйбыз һәм 3 - 5 көн эчендә, еш очракта янгын, авария яисә башка бәла көнендә үк страховой суммаларны түлибез. Биләр - Озеро авылында А.Починовскийга янып киткән өе һәм мөлкәте өчен 13 миллион сум акча түләнде. Кизләү авылында яшәүче Д.Сәлахов 10.000.000 сум акча алды. Урланган «Москвич»ы өчен Савельевага 7.800.000 сум түләнде, Кизләү авылында яшәүче И.И.Вәлиуллинга ватылган машина өчен 9.500.000 сум, Яңа Әмзә авылында яшәүче Ә.Камаловка янып киткән йорт янкормалары өчен 9.500.000, янган өе өчен Н.Ивановага 9.000.000 сум акча түләнде. 1996 елда үлгән мөгезле эре терлек өчен 68 миллион сум акча түләнде. Узган ел страхованиенең барлык төрләре буенча 891, быелның беренче кварталында 289 миллион сум акча түләү үткәрелде.

Без страховать ителүчеләргә страхование хезмәтләренең барлык төрләрен тәкъдим итәбез. «Росгосстрах - Татарстан» страховой фирмасы филиалы - төзелгән килешү нигезендә теләсә нинди страховой вакыйга уңаеннан зыянны капларга әзер ышанычлы партнер.

**Н.СИНДРЯКОВ,**
**Октябрь филиалының әйдәп баручы белгече.**

# КОТЛЫЙБЫЗ!

Кадерле әтиебез **Вахит Барый улы Җамалиевка** 9 июньдә 40 яшь тула. Без аны юбилее белән чын күңелебездән котлыйбыз.

Сәламәт бул, гел шат яшә,
Бәхет кунсын күңелең түренә.
Барыбызга канат, терәк булып
Талмый атла гомер түренә.
Тормыш маягы син безнең өчен,
Кешелегең белән үрнәк син.
Мең, мең рәхмәт тәрбияңә, әти
Безнең өчен һәрчак кирәк син.
**Тормыш иптәшең, балаларың.**



*Бикколавылында яшәүче әниебез **Миннегөл Хамматовага** 70 яшь. Әни, без сиңа озын гомер, нык сәламәтлек телибез.*

*Олыгайдым инде, кирәк бетте димә,*
*Кирәк, әни, кирәк син безгә.*
*Авырлыклар килсә, киңәш сорап*
*Киләбез без изге нигезгә.*
***Малайларың, килennнәрең,** *



## Белдерүләр

## Предприятие, оешма, учреждение җитәкчеләре һәм халык игътибарына!

Шәһәрдә һәм районда электр үткәргечләрнең югары вольтлы һава линияләре промышленность, коммуналь - көнкүреш һәм авыл хуҗалыгы предприятиеләрен электр энергиясе белән тәэмин итүгә хезмәт итә. Электр челтәрләрен саклау кагыйдәләре нигезендә 1000 вольттан югары көчәнештәге үткәргечләр янында югары линияле үткәргечнең соңгы чыгырыннан ике якка да 10 метрдан 30 метрга кадәр саклагыч зона булуы шарт.

Бу саклаулы зоналарда электр челтәрләре предприятиеләренең язма рөхсәтеннән башка

- төрле биналар һәм корылмаларны төзү, капиталь ремонтлау, реконструкцияләү яки сүтү;
- агач яки куаклыклар утырту яки кисү, кыр станнары ясау, көтү йөртү;
- юл өслегеннән гомуми биеклеге 4,5 метр булган машина һәм механизмнарның үтүе тыела.

Электр челтәрләренең нормаль эшен бозуга, аларны зарарлауга яки бәхетсезлек очракларына китерә торган барлык эшләр башкару тыела. Аерым алганда:

- саклаулы зоналарда ягулык станцияләре урнаштыру;
- электр челтәрләре объектларына килү юлларын томалау;
- электр үткәргечләргә һәм баганаларга чит әйберләр ташлау, багана башына менү;
- бу зоналарда һәм алар янәшәсендә чүп урыннары булдыру;
- азык, салам, утын өю, учак кабызу тыела.

Бу таләпләрне үтәмәгән җаваплы кешеләр һәм гражданнар тиешле тәртиптә җаваплылыкка тартылалар. Хуҗалык җитәкчеләре үз территорияләрендәге электр линияләренең сакланышы өчен җавап бирәләр.

Бәхетсезлек һәм янгын очракларын булдырмау максатында һава линияләренең зарарлануы һәм саклаулы зонадан кагыйдәләрнең бозылуы турында Норлат РРЭСына (Подстанция) мөрәҗәгать итүегезне сорыйбыз.

Телефоннар: 2 - 25 - 24, 2 - 14 - 55.

**Норлат РРЭСы.**

## Акционерлар игътибарына!

«Девон - кредит» акционерлык банкы банкның исемле гади акцияләре буенча 1997 елның I кварталы өчен еллык 38,46 процент күләмендә дивидендлар түләнүе турында белдерә.

Дивидендлар:

физик затларга акчалата бирелә яки аларның теләге буенча банктагы шәхси счетларына күчерелә;

юридик затларныкы - акча күчерү өчен төгәл реквизитларны күрсәтеп язылган гариза нигезендә исәп -хисап счетларына күчерелә.

Дивиденд алуга 1997 елның 1 апреленә акционерлар реестрында торган акционерлар хокуклы.

Дивидендлар түбәндәге адрес буенча түләнә: Норлат шәһәре, Совет ур., 179 нчы йорт, тел.: 5 - 29-22, 65 - 2 - 27.

## Акционерлар игътибарына!

«Норлат - Октябрь элеваторы» акционерлык җәмгыяте акционерларының 12 июньгә билгеләнгән гомуми җыелышы, бу көннең бәйрәм көне итеп игълан ителүе сәбәпле, 20 июньгә сәгать 10га күчерелә. Үзең белән паспорт яки шәхесне раслаучы башка документ, акционерларның вәкилләренә -җыелышта катнашу хокукын. башка кешегә тапшыру турында ышанычлама алып килү шарт.

**Директорлар Советы.**

## Төзәтү

***"Дуслык" газетасының үткән 60 нчы санында "Безгә театр килә" башы астында чыккан язмада спектакль куеласы көннәрне май аенда түгел, ә июнь аенда дип укуыгыз сорала.***

## Белдерүләр

### Сатабыз

**3600 км. юл үткән «Урал» мотоциклы. Бәясе килешү нигезендә.** Тел.: 5 - 26 - 86.

***

**1992 нче елгы ВАЗ - 21083, 20 мил. сум.** Тел.: 5 - 25 - 35 яки «Автосервис»ка мөрәҗәгать итәргә.

***

**Йорт (участогы 12 сутый), яңа стенка, тәргәктә кухня гарнитуры, 1000 км. юл үткән «Муравей» мороллеры. Кыйммәт түгел.** Адрес: Киров ур., 9.

***

**Норлатта бер бүлмәле фатир.** Казанга 56 - 34 - 69 телефонына мөрәҗәгать итәргә.

**Сүтеп алу өчен 4,5 х 5,5 метрлы йорт, 4 х 5 һәм 3,5 х 3,5 метрлы буралар, кыйммәт түгел.** Яңа Тумба авылында Захаров Николай Михайловичка мөрәҗәгать итәргә. Тел.: 4 - 72 - 37.

***

**«Татпромстрой» банкының Норлат - Октябрь филиалы ашыгыч рәвештә кулдан түләү яки күчерү юлы белән исәпләшү шартында Әфган поселогында 10 сутый участогы белән төзелеп бетмәгән кирпеч йорт сата.** Тел.: 2 - 24 - 95, 8дән 17 сәг.кә кадәр.

### Алмаштырабыз

**1 бүлмәле фатирны - өстәмә түләп ике бүлмәлегә.** Арадашчы тел.: 5 - 27 - 19.

БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2089 данә. Заказ N 7207